Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

_____09.06.2023_____

Менделеевск ш.

№ _____343_____

“2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру,
физик культураны һәм спортны популярлаштыру,
алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү”
район муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 декабрендәге 1338 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган югары куркыныч чыганакларының урнашу урынын билгеләү турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны популярлаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» район муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “Программа паспортын эшләү өчен нигез” пунктында “Татарстан Республикасында халык арасында алкоголь продукциясен, сыраны, тәмәке куллануны һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы карары” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының mendeleevsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Ш.Ханзаровка йөкләргә

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

социаль мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары Д.Ш. Ханзаров

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева